**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

12 май 2022 ел №18-07

**«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы милкендәге, өченче зат хокукларыннан азат булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген раслау турында» Актаныш муниципаль районы Советының 2016 елның 04 августындагы 08-07 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм итү максатларында, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы милкендәге, өченче зат хокукларыннан азат булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә, 1 нче кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында (www.Aktanysh.tatarstan.ru ) һәм "Актаныш таңнары" район газетасында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитетына йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы Советы рәисе Э.Н. Фәттахов

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы Советы
карарына 12 май 2022 ел, №18-07
кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы милкендәге, өченче зат хокукларыннан азат булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеге**

| Объектның урнашу адресы | Күчемсез милек объектының төре; күчемле мөлкәт | Күчемсез милек яки аның өлеше турында мәгълүмат | | | | | | | 0 | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Кадастр номеры | | Күчемсез милек дәүләт кадастры мәгълүматлары нигезендә күчемсез милек объектының бер өлеше номеры | 0 | | | Исәпкә алу объектының исеме | | | | | | |
| | | Номеры | Тибы (кадастр, шартлы, искергән) | | Тибы (җир участоклары, биналар, бүлмәләр өчен- мәйдан; озынлык, күләм, мәйдан, яту тирәнлеге һ.б. - корылмалар өчен; озынлык, күләм, мәйдан, яту тирәнлеге һ.б. проект документациясе нигезендә - төгәлләнмәгән төзелеш объектлары өчен) | Фактик әһәмияте/ проектлана торган әһәмияте (төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары өчен) | Үлчәү берәмлеге (мәйдан өчен- кв. м; озынлык өчен-м; тирәнлек өчен - м; күләме өчен- куб. м | | Тибы: җиһазлар, машиналар, механизмнар, җайланмалар, транспорт чаралары, инвентарь, | Дәүләт теркәү билгесе (булганда) | Исәпкә алу объектының исеме | Маркасы, моделе | Чыгарылыш елы | Күчемсез милек объектының, шул исәптән объект урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| 3 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 |
| ТР, Актаныш районы, Актаныш ав., Ленин пр., 58 й. | күчемсез милек | | | | мәйданы | 97,27 | кв.м. | Актаныш авыл башкарма комитеты бинасында торак булмаган биналар | | | | | | |